**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 5 июнь № 420

г. Казань

«Росток» психологик-педагогик тернәкләндерү һәм коррекция үзәге» психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен дәүләт автоном белем бирү учреждениесенең исемен үзгәртү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Росток» психологик-педагогик тернәкләндерү һәм коррекция үзәге» психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен дәүләт автоном белем бирү учреждениесе исемен «Росток» психологик-педагогик тернәкләндерү һәм коррекция үзәге» психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен дәүләт автоном учреждениесенә (алга таба –Үзәк) үзгәртү турында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тәкъдимен кабул итәргә

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына 30 көн эчендә Үзәк уставын эшләргә һәм расларга.

3. Үзәк тарафыннан дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү күрсәтелгән максатларга тиешле финанс елына һәм планлаштырылган чорга Татарстан Республикасы бюджеты турында законда каралган акча кысаларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә мөнәсәбәттә дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2010 ел, 29 апрель, 308 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карар кабул ителү белән бәйле «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисади һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә Үзәк уставы расланганнан соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Үзәк исемен әлеге карарның 1 пунктына яраштыру өлешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2014 ел, 10 декабрь, 974 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәр тапшырырга.

5. Бу караның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\420.doc